# Җөмләнең иярчен кисәкләре. Аергыч



***Татар теле*** ***7 нче сыйныф***

# Җөмләнең баш кисәкләре

Ия
(подлежащее)

Хәбәр
(сказуемое)

# Җөмләнең иярчен

- аергыч
- тәмамлык
- хәл

АЕРГЫЧ

- НИНДИ?
- КАЙСЫ?
- КЕМНЕҢ ?

# Мисаллар:

- Энем зур алма ашый.
- Алсу бишенче этажда яши.
- Укучылар кызыклы китап укый.
- Бәйрәмдә кызларның күлмәкләре матур иде.
- Тырыш һәм акыллы укучылар гына бишлеләргә укый.

# ҖӨМЛӘДӘГЕ СҮЗЛӘР ТӘРТИБЕН ДӨРЕС УРНАШТЫР.

- Мөнир, сыйныфта, бишенче, укый.
- әтисе, кибеттән, яңа, Мөниргә, велосипед, алды
- янына, Мөнир, якын, җыелды, дуслары.
- мактанасы, килде, велосипед, белән, Аның.
- тәгәрмәче, Велосипедның, уңга, борылды.
- Чыршы, яшел, калды, артта.

# ТИКШЕРҮ.

- Мөнир бишенче сыйныфта укый.
- Мөниргә әтисе кибеттән яңа велосипед алды.
- Мөнир янына якын дуслары җыелды.
- Аның велосипед белән мактанасы килде.
- Велосипедның тәгәрмәче уңга борылды.
- Яшел чыршы артта калды.


# БЕЗ ӘДӘПЛЕ БАЛАЛАР.


- Олы кешеләрне ихтирам итәргә кирәк.
- Кечкенә балаларга шәфкатьле булырга кирәк.
- Барлык кешеләргә әдәпле эндәшергә кирәк.
- Миңа тырыш кешеләр ошый.
- Тәрбияле кешене һәркайда яраталар.

# ӨЙ ЭШЕ.

- 57 бит, кагыйдәне өйрәнергә.
- 58 бит, 7 күнегү.







Кешеләрне ярат, әйбәт гадәтле бул!
Сабыйларны кыерсытма, әдәпле бул!
ихтирам ит, олыларны кечеләрне,
Яшьтән өйрән яратырга кешеләрне!
Очрашканда исәнләш син – телең
калмас,
Ата-ана хакын хакла, тел тидермә
Тыңлаучан бул, каршы әйтеп җан
көйдертмә.
Олыларның фарыз, балам, күңелен
күрмәк,
Ярдәм итеп өйләренә барып йөрмәк
Тәрбияң дә, укуың да булса үрнәк,
Үзеңә дә бик тиз килер кадер-хөрмәт.

# Сау булыгыз!



# Җөмләләр

- Тәрбияче балалар белән урамга чыга.
- Әдәпле бала олыларны хөрмәт итәргә тиеш.
- Бүген укучыларның дәфтәрләре җыелмады.
- Ял көне әтием белән кызыклы һәм мавыктыргыч китаплар укыдым.